РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

17.03.2017 | № 277-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлешенигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының элегрәк әзерләнгән һәм расланган Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләренең проектын әзерләүгә керешергә.
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрендә төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия төзергә.
3. Расларга:
   - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе составын (кушымтада бирелә);
   - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә).
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары Э.Д.Рамазановка йөкләргә.

Җитәкче | Р.М. Гасимов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 мартындагы 277-п номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Гасимов Р.М. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе комиссия рәисе; |
| Рамазанов Э.Д. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Вәлиәхмәтов И.Р. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары | |
| Галиуллин А.М. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Миникаев А.И. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сөнгатуллин Р.Р. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» РДУПнең Саба участогы башлыгы (килешү буенча); |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары | Карала торган Җирдән файдалану һәм авыл җирлеге төзелеше кагыйдәләренең территориаль буйсынучанлыгына карап |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 17
мартындагы 277-п номерлы карары
белән РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының
Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләре
проектын әзерләү комиссиясе турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

**1.1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасын камилләштерү һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен төзелә.

**1.2.** Комиссия Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә

**1.3.** Комиссия Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә даими эшли һәм эшчәнлек алып бара.

## 2. Комиссия составы

**2.1.** Комиссия составы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана.

**2.2.** Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын рәис урынбасары башкара.

## 3. Комиссия компетенциясе

**3.1.** Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

**3.1.1.** Җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасын эзлекле формалаштыру һәм камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү, ә алга таба аларны гамәлгә ашыру.

**3.1.2.** Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләргә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау.

**3.1.3.** Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү.

**3.1.4.** Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр һәм тәкъдимнәр әзерләү, аларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә район башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрү.

## 4. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

**4.1.** Комиссия гариза килгәннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча җыела.

**4.2.** Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

**4.3.** Комиссия карары шунда булган комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора. Комиссия карары тәкъдим итү характерына ия.

**4.4.** Комиссия эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының башкарма комитетына йөкләнә.

**4.5.** Комиссия, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында тәкъдимнәр кергән көннән алып 30 көн эчендә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, мондый тәкъдимне кертү яисә кире кагу турында бәяләмә әзерли һәм бу бәяләмәне, карар кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетына җибәрә:

– җирдән файдалану һәм гавами тыңлауларга төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча материалларны җибәрү турында;

– җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында кергән гаризаны кире кагу турында.